# КАЙТАМ ТУГАН ЯГЫМА

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Чит илләрдән туган илгә
Кайтып киләм ашкынып,
Каршы искән шаян җилгә
Сәламемне тапшырып.

Сәлам сиңа, илкәем,
Туып үскән җиркәем!
Сәлам сезгә, авылым,
Басуларым, кырларым!

Качып киткән улыгыз
Кайта – каршы алыгыз!
Гафу итә күрегез
Һәм үпкәләмәгез!

2. Туган йортымның учагы
Калса да ерак миннән,
Әнкәйнең җылы кочагы
Чыкмады күңелемнән!

Сәлам сиңа, әнкәем!
Сәлам, газиз әткәем!
Сәлам сезгә, абыем,
Апаларым, әбкәем!

Качып киткән улыгыз
Кайта – каршы алыгыз!
Гафу итә күрегез
Һәм үпкәләмәгез!

3. Истә калды кыр казларның
Һавадан үткәннәре,
Киткәнемдә яшь кызларның
Кочаклап үпкәннәре!

Сәлам сиңа, Әлфия!
Кара кашым – Зөлфия!
Гөлфия, Гүзәлия,
Рузалия-гөлкәем!

Югалган абзыегыз
Кайта – каршы алыгыз!
Гафу итә күрегез
Һәм үпкәләмәгез!

4. Чаба поезд, чак-чок итеп.
Озакламый җитәрмен.
Жырның ахырына җитеп,
Шагыйрьләрчә әйтермен:

Һинд илендә филләр күп,
Жир йөзендә илләр күп.
Арасында бай илләр,
Матур илләр дә бик күп.

Тик белмәс тинтәк кенә:
Туган як – ул бер генә!
Ни җитсен туган туфрагыңның
Исләренә?

Туган ягыма кайтам!

**Возвращаюсь в родные края**

Шаловливая песня от лица парня, который тайком уехал из своей деревни и теперь возвращается в родные края. По пути он мысленно представляет свою встречу с близкими людьми и просит у них извинения за свой побег.